YouTube-канале «Татар-информ». – 2021. – 06 окт. – [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://www.youtube.com/watch?v=bh60PbBDuzc (дата обращения: 27.10.2021).

9. Лэйна – псевдоним, шәхси тормышы, эстрада һәм яңа дуэт турында / Интервью с певицей // Проект «Казаныш» на YouTube-канале «Ялкын». – 2021. – 23 мая. – [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://www.youtube.com/watch?v=Widw1-logm4 (дата обращения: 27.10.2021).

10. Айдар Ракипов – Казан, кызлар һәм хоббилар турында ЭКСКЛЮЗИВ интервью // Проект «Сораштырлаштыргалау» на YouTube-канале «Ялкын». – 2019. – 7 окт. – [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://www.youtube.com/watch?v=3os-y1Vc3jo&list=PLJOWDFHqeHwEyRV8brbacgWsfD5NBzCg6&index=4 (дата обращения: 27.10.2021).

11. Ришат Төхвәтуллин // Проект ««Ничек бар – шулай» на YouTube-канале «Сююмбикэ/Сөембикә журналы». – 2020. – 28 мая. – [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://www.youtube.com/watch?v=7YKAHNpG-dw (дата обращения: 27.10.2021).

***А. Р. Сабирова***

Казанский (Приволжский) федеральный университет

©А. Р. Сабирова

***Р. Л. Зайни***

канд. филол. наук, доцент

Казанский (Приволжский) федеральный университет

©Р. Л. Зайни

## ТЕНДЕНЦИИ ФОРМИРОВАНИЯ КОНТЕНТА ТАТАРСКИХ СМИ В СОЦИАЛЬНЫХ СЕТЯХ

## ТАТАР ГМЧЛАРЫНЫҢ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ КОНТЕНТ БУЛДЫРУ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

***Аннотация.*** *В настоящее время СМИ не ограничиваются деятельностью на традиционных платформах, но и* *сотрудничают и с социальными сетями. Социальные сети стали*

*популярной площадкой для создания, размещения и развития медиаконтента, что отвечает требованиям времени: многие следят за событиями в мире и стране с помощью социальных сетей. Актуальность социальных сетей для профессиональной коммуникации, и, в особенности, для СМИ велика, а умение работать с ними очень важно для современных журналистов. Интеграция традиционных видов СМИ, то есть печатной прессы, радио и телевидения, в социальные сети, создание контента представляют двойной интерес. За российскими СМИ не отставала и татарская журналистика, и на данный момент мы имеем богатую, но в то же время требующая изменений и поправок базу для проведения анализа.*

***Ключевые слов:*** *социальные сети, СМИ, аудитория, медиареальность.*

***Abstract.*** *Currently, media sources are not limited to activities on traditional platforms but are branching out into social networks. Social networks have become a popular platform for the creation, placement and development of media content, many now follow the media through social networks. «The huge growth, their popularity, large reach, new forms of communication and information transfer processes have changed the global network. The relevance of social networks for professional communication, especially for the media, is low and the ability to work with them is very important for modern journalists». In connection with the above, we can say that the study of social networks as a platform for modern Internet media refers to the requirements of the time. The integration of traditional types of media, that is the print press, radio and television, into social networks, the creation of content is of double interest, since for them in recent years it has been perceived as a real innovation. Tatar journalism has not lagged behind the Russian media, and at the moment we have a large rich but at the same time requiring changes and amendments a base for analysis.*

***Keywords:*** *social networks, media, audience, media reality.*

Хәзерге заманда гаммәви мәгълүмат чыганаклары традицион платформалардагы эшчәнлеге белән генә чикләнеп калмый, ә социаль челтәрләргә дә тармаклана. Ул медиаконтентны булдыру, урнаштыру һәм үстерү өчен популяр мәйданга әверелде, күпчелек, гадәттә, ГМЧ артыннан социаль

челтәрләр ярдәмендә күзәтеп бара. Социаль челтәрләрне заманча интернет-ГМЧ өчен платформа буларак өйрәнү заман таләпләренә кирә дисәк тә була. ГМЧларның традицион төрләренең, ягъни басма матбугат, радио һәм телевидениенең, социаль челтәрдәге интеграциясе, контент булдыру икеләтә кызыксыну уята. Рус ГМЧлары артыннан татар журналистикасы да калышмады һәм, анализ башкарыр өчен зур, бай, ләкин шул ук вакытта төзәтмәләр, яңалык кертерлек базага ия.

Интернет социаль челтәрләре бүгенге вәзгыятьтә кешелек тормышының аерылгысыз бер өлешенә, аңа көн дәвамында кирәкле яисә мөһим булмаган мәгълүматне тапшыручы механизмга, системага әверелде. Бу үзгәрешләргә социаль пәрәвезнең аерылгысыз бер функциясе – коммуникатив функциясе сәбәпчел булды.

Социаль челтәрләрдә без шәхси аккаунтларыбызны булдырабыз, кызыксынулар буенча төрле төркемнәргә бүленәбез һәм зур коммуникация системасында катнашабыз. Әлеге аңлатма кешелеккә салынган табигате белән тәңгәл килә һәм интернет социаль челтәрләренең барлыкка килүенең көтелмәгән күренеш түгел икәнен исбатлый. Димәк, социаль челтәрләр – кеше мөнәсәбәтләренең аерылгысыз атрибуты.

Ләкин бүгенге көндә интернет социаль челтәрләрен бары коммуникатив функция белән чикләргә ярамый. Хәзерге вакытта алар түбәндәге функцияләрне үти: үз-үзеңә презентация ясау, платформаны кулланучыларның үзара бәйләнеше, социальләшү функциясе, ресурслар белән алмашу, мәгълүмат үзләштерү, медиафайллар һәм аудиофайллар карау, кооперация, үз-үзеңне рухи һәм физик яктан үстерү мөмкинлеге, кабул иткән ресурслар ярдәмендә үзеңне канәгатьләндерү мөмкинлеге, күңел ачу функциясе.

Интернет социаль челтәрләренең функцияләренең төрлелеге һәм бер платформада сыеша алуы алдагы фикергә юнәлтә: теләсә нинди онлайн форматта эшләүче социаль челтәрләр, беренче чиратта, техник платформа булып санала. Аның нигезендә теләсә нинди контент (челтәр тыелган контенттан тыш) урнаштырылырга мөмкин, һәм ул гамәлдәге субъектның ихтыярына карап төрле максатларда файдаланыла ала.

Социаль челтәрләр бүгенге вәзгыять, кешенең тормышы белән кысан элемтәгә керде һәм конкрет шәхеснең билгеле бер

кызыксынуларын чагылдырган платформага әверелде. Мондый үзгәрешләрне гаммәви мәгълүмат чаралары читләтеп уза алмый, чөнки алар кысан рәвештә социаль мөнәсәбәтләр белән үрелеп бара.

Татарстан ГМЧларының социаль челтәрләрдә нигез булдыруы акрын темп, саклык белән башланды, алып барылды һәм хәзерге вакытта алар үзенә тотрыклы мәйдан әзерләде, үзенә тугры аудиториясен туплады.

Татар ГМЧларының социаль челтәрләрдә формалашуының беренче этабында социаль пәрәвезгә материалларны урнаштыру күпкә соңга калынып башкарылды. Ләкин хәзер милли медиа вәкилләре аудиториянең күп өлеше Интернетта икәнен аңлады. Шуңа кайбер очракта, гадәттә, оперативлык өчен, төп яңалык яисә материал, беренче чиратта, социаль челтәрдә урнаштырыла, аннары гына сайтта. Яисә социаль челтәр өчен аерым контент әзерләнә.

Татарстан Республикасының күпчелек мәгълүмат чаралары социаль челтәрләрдә үз эшчәнлеген алып бара. Кайберәүләре контент һәм җәлеп итү ысуллары белән бер урында таптанса, күбесе яңа алымнар куллана, контентны замана белән үзгәртергә тырыша. Күзәтү буенча, татар ГМЧларының контент урнаштыру өчен еш куллана торган социаль челтәрләренең берсе мәгълүм вакыйгаларга кадәр Instagram (Россиядә тыелган социаль челтәр) эшчәнлеге Россиядә экстремистик буларак тыелган) булды, шулай ук ВКонтакте актив эшләде. Бүгенге көндә әлеге исемлеккә TikTok һәм YouTube та кереп бара. Одноклассники, Facebook (Россиядә тыелган социаль челтәр) социаль челтәрләрендә милли медиаларының битләре еш очрамады, берничә генә мисал китереп була.

Һәр социаль челтәр өчен уникаль, аңа хас һәм аудиториясенә туры килерлек контент кирәк. Шуңа татар ГМЧларының социаль челтәрләрдәге интеграциясен тикшерер өчен, аларның һәр платформадагы эшчәнлегенә күзәтү ясау зарури. Шул максаттан ММЧның өч төренә туры килгән мәгълүмат чарасы каралды: «Ватаным Татарстан» газетасы, «ТНВ» телеканалы һәм «Тәртип» радиосы.

Әлбәттә, XXI нче гасырда ММЧ төрләренең исемлегенә Интернет-басма да кушыла. Тик шуны истә тотарга кирәк – Интернет киңлегендә формалашкан басмаларга социаль

челтәрләргә интеграцияләнү күпкә җиңел бирелде. Безне, иң беренче чиратта, формат һәм мәгълүмат тапшыру буенча цифралаштырган технологияләрдән ерак булган, һәм шул ук вакытта социаль челтәрләрдәге эшчәнлеген яхшы темп белән алып барган басмалар кызыксындыра.

Тикшеренүчеләр аңлатуы буенча, социаль челтәрләрдә аудиторияне арттырып, газета-журналларның битләре бүгенге басма журналистиканың төп проблемасын – тиражлар төшүен һәм рекламадан килгән керемнең кимүен компенсацияли. Татарстан ГМЧлары да нәкъ шушы функцияне куллана. Шуларның берсе – «Ватаным Татарстан» газетасы.

«Ватаным Татарстан» – Татарстан Республикасының татар телендә чыгучы, 100 елдан артык тарихы булган иҗтимагый-сәяси газетасы. Аның аудиториясе 20 дән 80 яшькә кадәрге укучылар дип фаразлана. «Безне авыл һәм шәһәр халкы, дәүләт структуралары, җитәкчеләр һәм гади эшчеләр, пенсионерлар, эшмәкәрләр, иҗат интеллигенциясе – кыскасы, бөтен Татарстан укый» дип белдерелгән аларның сайтында.

Димәк, «Ватаным Татарстан»ны укучылар социаль статус, яшь, җенес, һөнәр һәм башка социаль бүленүләр белән аерылып тора. Ә бу, үз чиратында, төрле аудиторияне җәлеп итәр өчен төрле каналлар, социаль челтәр платформалары кирәк дигәнне аңлата. Бу – «Ватаным Татарстан»ның төрле социаль челтәрләргә таркалуын билгели дә.

Газетаның ВКонтакте төркемендә (https://vk.com/vatanym) барлыгы 26 мең кеше җыелган. Нәкъ шушы аудитория өчен «Ватаным Татарстан»ның төркеме басма матбугат өчен актив эшен алып бара дигән нәтиҗә ясыйбыз. Аудитория дә куелган контентка үз реакциясен бирә: уртача язма астында 100 лайк куела һәм 10 нан 50 кадәр комментарий языла.

Төркемнең башында редакция тарафыннан каршы алу тексты урнаштырылган: «Ватаным Татарстан» газетасында чыккан, әле чыгарга өлгермәгән һәм чыкмаска да мөмкин иң кызыклы язмалар, яңалыклар хәзер монда эленә». Димәк, ВКонтакте төркеме газетага гына бәйләнмәгән, ә күбрәк сайт белән элемтәдә. «Шапка»да редакция номеры һәм сайтка сылтама бирелгән.

ВКонтакте контенты сайт белән тәңгәл килә дисәң бер дә хата булмас. Материаллар фото һәм текст белән куела.

Яңалыклар гына түгел, ә җәлеп итүче язмалар бар. Мәсәлән, җырчы Ришат Төхвәтуллинга багышланган язмада аның популяр җырлары тезелгән. Төркемдә шулай ук видео, бүтән социаль челтәрләргә сылтама, подкастлар да тәкъдим ителә.

«Ватаным Татарстан» ның Instagram (https://www.instagram.com/vatanymtatarstan - Россиядә тыелган социаль челтәр) битенә барлыгы 37 мең кеше язылган иде. Профильның шапкасы болай бирелә:

Ватаным Татарстан

СМИ/информационное агентство

«Ватаным Татарстан» газетасы

WatsApp 89179270040

Борчыган сорауларыгыз, проблемаларыгыз булса ЯЗЫГЫЗ

taplink.cc/vatanymtatarstan.

Әлеге мәгълүматлардан соң бик күп беркетелгән «сторизлар» килә. Алар рубрикалар буенча бүленгән: «Бәйге», «Сәламәтлек», «Киңәшләр», «Хәбәрләр», «Спорт», «Рецептлар», «Халык авазы», «Короновирус», «Дин», «Кайсыгызның кулы җылы», «Язылырга», «ТАССР 100», «Корпоратив», «Уку бәйрәме», «ВТ»да кунакта» һ.б. Шулай ук аккаунтта язмаларны, туры эфир, кыска видеоларны да карап була.

Соңгы елда «Ватаным Татарстан» постларны кыска видео форматында куеп барды. Соңгы күзәтүләр буенча, постлар бу алым белән күбрәк укучыны яулап ала, постны укырга этәрә. Язмалар газета форматына туры килә һәм дизайнына тәңгәл килә.

Мәгълүмати контент белән бергә күңел ачу материаллары бергә үрелеп бара. Күңел ачу контентына төрле рецептлар, җырчыларның чыгышлары, халык җибәргән җәлеп итәрлек видеолар, йолдызнамәләр һәм матур видеолар керә. Алар, комментарийларны күбрәк алса, мәгълүмати контентта комментарийлар юк дәрәҗәсендә.

«Ватаным Татарстан»ның «Одноклассники»дагы төркеменә (https://ok.ru/profile/573463937887) 967 кеше язылган. Аккаунтта барлыгы 7547 фото, 7841 язма бирелә.

Әлеге социаль челтәр бик популяр булмаса да, газета аккаунтны бик актив алып бара. Ул бик еш төрле материаллар, фото, видео, реклама белән яңартылып тора.

Газетаның Telegram бите (https://web.telegram.org/z/#-1423927833) бик популяр түгел. Биредә бары тик 1 меңнән артык

кулланучы бар. Аккаунттагы материаллар турыдан-туры сылтама (Фаҗигагә ачыклык кертәбез: https://vatantat.ru/2021/03/48530/) яисә түбәндәгечә (Республика транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов җирле халыктан алынган шундый тәкъдимне хуплаган) бирелә. Канал күптән түгел барлыкка килгәнгә, биредә әлегә укучылар бик күп түгел. Шулай да аның актив алып барылышы газетага укучыларны өстәр дип уйлыйбыз.

Газетаның YouTube аккаунты (https://www.youtube.com/channel/UC3N3h2JtFHWQF306WGw9fBw/about) видеолар карарга, комментарийлар калдыру өчен тудырылган, дип исәплибез. Акаунтка 228 кеше язылган. Ул 2016 елда барлыкка килә. Барлыгы 70766 кеше видеоларны караган. Проект газета материалларын кабатлап кына калмый, ә махсус проект «Бөекләр эзеннән» тапшыруын да чыгарып бара. Караулар санына килгәндә, алар күп түгел, ә 1 алып 719 га («Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренә штрихлар) кадәр.

«Тәртип» радиосының социаль челтәрләренә тукталырбыз. «Тәртип» – татар милли мәдәниятенең чын кыйммәтләрен саклап калу һәм таныту максаты белән эшләүче уникаль контентлы радио» дип язылган радионың төп сайтында. «Тәртип» радиосы соңгы елларда яңа тормышы белән яши һәм, нәтиҗәдә, социаль челтәрләрдә үзен күрсәтә башлады, үсеш юлына басты.

«Тәртип» радиосының ВКонтакте битендә (https://vk.com/tartip.tatar) барлыгы 10 меңләп язылучы. «Шапка»сында радионың канатлы сүзләре теркәлгән: «Тәртипле халык югалмый, татар тәртипсез була алмый!». Шулай ук официаль сайтка сылтама, редакция вәкилләре язылган.

Контент ягыннан «Тәртип» радиосының ВКонтакте төркеме төрлелеге белән куандырды. Биредә яңа тапшыруларның, яңа проектларының анонслары, радиога киләчәк һәм килгән кунакларның фотосурәтләре куелган. Өстәвенә, җәлеп итүче һәм күңел ачу контенты да үз урынын алып тора. Мәсәлән, 9 февраль көнне куелган Фәнис Яруллинның цитатасы, җырчыларның җыр исемлеге, радио белән бәйле төрле чаралардан фотолар.

«Тәртип» радио калыпларын социаль челтәрләрдә дә саклап калырга тырыша. ВКонтакте төркемендә плейлистлар бүлеге ярдәмендә бу икеләтә җиңел чынга ашырыла. Радио эфирларын саклап калдырып, төркемдә темалар буенча бүленгән 604 подкаст

теркәлгән. Исемнәре, тематикасы радио тапшыруларына тәңгәл килә.

Подкастлар бүлеге белән беррәттән плейлист та атна саен яңарып бара. Килгән кунаклар, экспертлар яисә билгеле бер теманы яктырткан программалар саклана, аудио форматы белән төркемдә урнаштырыла. Әлеге алым тапшыруны тыңламый калган кешегә бик зур ярдәм күрсәтә. Димәк, аудитория белән элемтә дөрес урнаштырылган.

Битне анализлаганнан соң, алдагы фикергә килеп була: ВКонтакте төркемендә «Тәртип» үзенең радио эшчәнлегенә игътибар юнәлттерә, аның эшчәнлеген һәм яңа проектларын әлеге социаль челтәр аудиториясенә тәкъдим итә. Төркем радио белән тыгыз бәйләнештә, ул аерым функцияләнми.

«Тәртип» радиосының Instagram (Россиядә тыелган социаль челтәр) бите актив булды. 25 мең язылучы әлеге социаль челтәр ярдәмендә радио эшчәнлеген күзәтеп бара. Биредә эфирга килгән кунаклар белән өзекләр, бәйрәмнәргә бәйле постлар, тапшыруларга һәм проектларга анонслар, цитаталар һәм кызыклы рубрикалар.

Кызыклы рубрикалар тупланган аудиторияне күңел ачу һәм потенцаль яңа аудиторияне җәлеп итү максатыннан эшләнелә. Мәсәлән, «Татар җырларында еш очрый торган сүз», «7 мәкаль», «Сүрәләр», «Еллар белән сыналган җыр» һәм «Ә мин бу җырны бер хәрефтән таныйм!» уены. Кызганыч, комментарийлар постлар астында еш очрамый, уртача 5тән 34 кә кадәр тәшкил итә.

«Актуальное» өлешендә радиога кагылышлы мәгълүмат, шулай ук алар алып барган проектларда катнашучылар, кагыйдәләре һәм редакция мәгълүматлары куелган.

Алда әйтелгәнчә, «Тәртип» радиосы яңа формат белән соңгы елларда гына эшли башлады. Шуңа социаль челтәрләрнең киңлеге зур түгел, ул 2 платформа белән чикләнеп тора. Бу күренешнең үсешнең беренче этапларында күзәтелүе куркыныч түгел. «Тәртип» бөтен игътибарын конкрет платформаларга юнәлтә һәм контент ягыннан сыйфатын саклап кала һәм уникальлеген югалтмый. Әлбәттә, бу озакка сузылырга тиеш түгел һәм аларга яңа мәйданнарга таралу ягын да кайгырта башларга кирәк.

«ТНВ» – ул хәбәрләр, иҗтимагый-сәяси тапшырулар, телесериаллар, ток-шоу, спорт матчларының турыдан-туры трансляцияләре, концертлар, театрлар һәм кичәләр» дип бирелә рәсми сайтта. «ТНВ»ның ВКонтакте, шулай Facebook һәм Instagram (Россиядә тыелган социаль челтәрләр), YouTube кебек медиа чараларында үз аккаунтлары бар.

«ТНВ»ның ВКонтакте төркемендә (https://vk.com/tnv_tatarcha) барлыгы 37 меңнән артык язылучы. Ул массакүләм аудиторияне җәлеп итү максатын күздә тота, шуңа күрә аккаунттагы мәгълүматлар сайт һәм тапшыруга реклама булып тора. Аңа ярдәмгә кызыклы баш исемнәр, фото, видеолар килә.

Язмалар, ягъни видеосюжетлар астында һәрвакыт кешеләр игътибарын җәлеп итә торган дискуссия күзәтелә. Вакыт узу белән аның тирәсендәге төрле спекуляцияләр белән түгел, ә мәгълүмат белән кызыксынучы укучылар саны барлыкка килүен күзәтәбез. Официаль бит рус телендә алып барыла, татарча алып барылган кушымта да бар.

Лайклар һәм комментарийлар турында сүз куертсак, аудитория белән элемтә тыгыз урнаштырылмаган. Лайклар саны уртача 2 якын, комментарийлар юк дәрәҗәсендә. Ләкин караулар саны 200дән 500 гә яисә күбрәк тәшкил итә. Димәк, 33 мең язылучының күбесе актив түгел, алар төркем тормышында катнашмый, күзәтүче ролен алганнар.

«ТНВ» каналының YouTubeтагы аккаунтында (https://www.youtube.com/c/tnvtatar/video) барлык тапшырулар да диярлек чыгып килә. Ул 2014 елда теркәлгән. Караулар саны 58 миллионнан артып китә һәм бихисап комментарийларга бай.

Шулай ук биредә «ТНВ»ның бүтән продуктларына сылтамалар да бирелә. Биредә «ТНВ. Татарча»га да сылтама тәкъдим ителгән. Ул 2018 елда теркәлгән һәм 40 меңнән артык язылучыга ия.

YouTube аккаунты «ТНВ» телекомпаниясе өчен бик мөһим эш башкара. Шуңа да карамастан, интернеттагы аудиторияне җәлеп итү өчен телеканалга контентның яңа форматлары белән экспериментлар кирәк, чөнки биредә эфирдагы тапшырулар гына бирелә. Махсус контент өчен тудырылганнары юк.

Каналның Facebook (https://www.facebook.com/tvtnv - Россиядә тыелган социаль челтәр) аккаунты ВКонтакте битенә

охшаш. Шулай ук биредә материаллар русча да, татарча да бирелә. Язмалар тулысынча тәкъдим ителми, тулырак уку өчен сылталма ярдәмендә сайтка күчәргә кирәк. Мәсәлән: «Бер-бер хәл» сериалы геройлары Алмаз һәм Эльвира йөриләрме?

Аккаунт белән файдаланучыларның уңай мөнәсәбәте ахыр чиктә телекомпания сайтына күчүгә китерә. Үз чиратында, төркемдә катнашучыларның күбесен кызыксындырган постларның тематикасы һәм тибы контент-планнар төзегәндә исәпкә алынганы күренеп тора. Биредә бөтен яңалык-хәбәрләр бирелми, ә укучыга кызыклы, кирәкле, актуаль булганы гына урнаштырылган. Лента видео, фотолар белән тулыландырылган.

«ТНВ» каналының Instagram (https://www.instagram.com/tvtnv - Россиядә тыелган социаль челтәр) битендә 152 мең кеше исәпләнелә. Шундый күләм булса да, комментарийлар юк, карауларны исәпләүгә мөмкинлек чыкмады. Әлеге социаль челтәрнең асылыннан кирегә китмичә, аның битендә фото һәм видеолар урнаштырылды. Билгеле, видеолар ешрак чагыла. Ул төрле сюжетлардан өзек буларак тәкъдим ителә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: «ТНВ»ның социаль челтәрләрдәге эшчәнлеге сайтка сылтама, реклама, укучыларны, караучыларны җәлеп итү, коммерция максатларында кулланыла.

Югарыда бәян ителгәннәрдән гомуми нәтиҗә ясарга мөмкин: ГМЧ сайтларда гына түгел, ә платформа сыйфатында социаль челтәрләрне дә актив кулланалар. Бу аларга билгеле бер өстенлекләр тудыра: аудиторияне колачлау, трафик булдыру, популярлыкны арттыру һәм активлыкны саклап калуга хезмәт итә.

**Әдәбият:**

1. Акопов А.И. «Веб 2.0» как явление и как проблема // Акценты. 2007. №1-2. – С. 8-13.

2. Браславец Л.А. Интернет-сервисы социальных сетей в современной системе средств массовой информации: дис. ...канд. фил. наук. – Воронеж, 2010. – 169 с.

3. Гарифуллин В.З., Закиров Л.Р. Интеграция национальных СМИ с социальными сетями (на примере СМИ республики Татарстан) // Вестник Марийского государственного университета. 2018. №3. – С. 136-145.